**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

15.01.2016 Яр Чаллы № 57

Тукай муниципаль районының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы
«Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы 1 п. нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә үзгәрешләр кертергә.

1.1. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә тәртип саклау җәмәгать пункты башлыгын кертергә.

2. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев